СОВЕТ
НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

СОВЕТЫ

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы, Арча
муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 16 » июль 2021 ел** **№ 37**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында 2018 елның 21 декабрендәге 102 номерлы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (16.04.2019 №107, 08.11.2019 № 132, 20.02.2020 №140, 14.08.2020 № 155, 08.12.2020 №15 үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында 2018 елның 21 декабрендәге 102 номерлы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (16.04.2019 №107, 08.11.2019 № 132, 20.02.2020 №140, 14.08.2020 № 155, 08.12.2020 №15 үзгәрешләр белән)түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 9 статьяның 9.1 пунктында 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9)Яллаучы (эш бирүче) вәкиленә Россия Федерациясе гражданлыгы, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (подданство) туктатылу турында муниципаль хезмәткәргә шул турыда билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданлыгы (подданство) туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәр итәргә;»;

2) 9 статьяның 9.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9.1 пунктча өстәргә:

«Яллаучы (эш бирүче) вәкиленә чит ил гражданлыгы (подданство) алу яисә гражданның чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алуы турында муниципаль хезмәткәр чит ил гражданлыгы яисә гражданның чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алган көннән биш эш көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәр итәргә;»;

3) 10 статьяның 10.1 пунктында 6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (подданство) туктатылу; »;

4) 10 статьяның 10.1 пунктында 7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) чит ил гражданлыгы (подданство) булу яисә яшәүгә рөхсәт, яки Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, гражданның чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;»;

5) 28 статьяның 28.1 пунктында 2 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Фәхретдинов Р.Ә.

СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ